КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге составына керүче Явлаштау торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

26.08.2022 ел                                                                                    № 1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»Татарстан РеспубликасыЗаконының 35 статьясы нигезендә,Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 28 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып 2022 елның 26 августында узган гражданнар җыенында «2023 нче елда Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Явлаштау торак пунктында балигъ булган, Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге составына керүче Явлаштау торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме? " мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Явлаштау торак пунктында балалар мәйданчыгы кору(участокны планлаштыру, кече архитектура формаларын урнаштыру, щепа җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 283 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 148 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 148кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге составына керүче Явлаштау торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.

«2023 нче елда Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Явлаштау торак пунктында Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге составына керүче Явлаштау торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 сум күләмендә үзара салым кертүгә" һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме? - дигән сорау буенча:

- Явлаштау авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау карарын кабул ителгән дип танырга.

2.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/evlashtay адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Явлаштау авыл
җирлеге башлыгы

Р.Х.Нуриев